РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Сосновского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423596, Нижнекамский район,
д. Благодатная, ул.Мира, 64

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Сосновка авыл жирлеге
Башкарма комитеты

423596, Түбән Кама районы,
Благодатная авылы, Тынычлык урамы, 64

тел./факс (8555) 33-14-17, электронный адрес: Sosnovskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.sosnovskoe-sp.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 елның 03 ноябрьдә

№ 9

«2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү максатларында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә «2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү» муниципаль программасын расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Н. Бурчин

Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитетының
2022 елның 03 ноябрьдән
9 номерлы карарына
кушымта

# «2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү һәм үстерү» программасы

ЭЧТӘЛЕК

Программа паспорты ........................................................................................................ 4

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр ........................................................................................ 6

2 бүлек. Сосновка авыл җирлегендә эшмәкәрлек һәм инвестицион климатка анализ ......................................................................................................................................... 7

3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары ............................................... 8

4 бүлек. Программаның төп принциплары ........................................................................ 9

5 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән чишү кирәклеген нигезләү ........................................................................................................................ 9

6 бүлек. Программа чаралары системасы ....................................................................... 11

7 бүлек. Программа белән идарә итүне оештыру (Программаны тормышка ашыру механизмы) ...................................................................................................................... 13

8 бүлек. Программаны тормышка ашыру барышын контрольдә тоту ......................................................................................................................................... 13

9 бүлек. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү ............................. 13

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программа исеме | «2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм үстерү» (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | - «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>-«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон<br>- «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;<br>- Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Сосновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына |
| Программа заказчысы | Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаны эшләүче | Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программа чараларын башкаручы | Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның төп максатлары | – Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең социаль-икътисади мәсьәләләрен хәл итүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм аларның ролен күтәрү өчен уңайлы шартлар тудыру;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының конкуренциягә сәләтлелеген тәэмин итү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлекнең гамәлдә булган субъектларын саклау һәм яңа субъектлар булдыру;<br>– җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәтләре белән базарның туендырылуы;<br>– Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) алга этәрүдә булышлык күрсәтү;<br>– халыкны эш белән тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлеккә талантлы яшьләрне һәм потенциаль идарәчеләрне ачыклау һәм җәлеп итү;<br>– Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге предприятиеләре җитештергән тулаем продукция күләмендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештергән товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) өлешен арттыру;<br>– кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларның салым керемнәрендә түләнгән салымнар өлешен арттыру. |
| Программаның бурычлары | – Сосновка авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын үстерү; |

| | |
|---|---|
| | – Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең конкуренциягә сәләтлелеген һәм инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру;<br>– иҗтимагый һәм һөнәри оешмалар һәм эшмәкәрләр берләшмәләренең ролен көчәйтү;<br>– сәнәгать - халык кулланышы товарлары җитештерү, азык-төлек (сөт, ит), милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып һөнәрчелек; авыл хуҗалыгы (крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү);<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>– Сосновка авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм Сосновка авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация һәм оештыру ярдәме күрсәтү;<br>– кече эшмәкәрлекне төрле өлкәләрдә: торак-коммуналь, төзекләндерү, ремонт-төзелеш, җәмәгать туклануы өлкәләрендә муниципаль заказларны үтәүгә җәлеп итү;<br>– коррупциягә каршы тору буенча чаралар төркемен гамәлгә ашыру һ. б. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2023-2027 еллар |
| Программаның төп чаралары исемлеге | – кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартларны камиллләштерү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасы эшчәнлеген тәэмин итү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультация һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә социаль яклау һәм хезмәтне саклау механизмнарын эшләү һәм гамәлгә кертү. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре | – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлектә уртача хезмәт хакы күләмен уртача тармак дәрәҗәсенә кадәр арттыру;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен арттыру;<br>– җирлек инфраструктурасын үстерү һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту;<br>– үзебездә җитештерелгән товарлар, үз көчләре белән кече һәм урта бизнес оешмалары тарафыннан башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләмен арттыру;<br>– продукцияне сату базарын киңәйтү;<br>– җирлектә гаилә терлекчелек фермалары саны, авыл хуҗалыгы терлекләренең баш саны арту;<br>– авыл җирлеге бюджетына кече эшмәкәрлек |

| | |
|---|---|
| | субъектларыннан кергән керемнәр өлешен арттыру;<br>– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын методик тәэмин итү хисабына югары мәгълүмати активлык һәм хәбәрдарлык<br>– эшсезлек дәрәҗәсен киметү;<br>– хакимияткә ышанычны ныгыту, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм җирлекнең җирле үзидарә органнары арасында эшлекле мөнәсәбәтләрне үстерү |
| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, район, муниципаль берәмлек, бюджеттан тыш фондлар һәм җәлеп ителгән инвестицияләр чаралары. |
| Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы | Сосновка авыл җирлеге Башкарма комитетының программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәләренә ел саен анализ ясау ярдәмендә башкарыла торган Программаны тормышка ашыру мониторингы. |

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Программа «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ), «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 209-ФЗ), «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә эшләнгән.

131-ФЗ нигезендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү мәсьәләләре керә.

209-ФЗ кабул итүгә бәйле рәвештә, җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (алга таба - КУЭС) үсеше өчен шартлар тудыру кертелде.

Программа объекты булып, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр, шулай ук һөнәри керемгә салым махсус салым режимын кулланучы физик затлар тора. Җайга салу предметы - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль ярдәм күрсәтү.

Әлеге Программаның максатлары һәм төп бурычлары Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Программа Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген, чараларны тормышка ашыру өчен җаваплыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын, эшчәнлек нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен билгели.

Программа Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең 2023-2027 елларга кадәр социаль-икътисади үсеше фаразында каралган Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш өстенлекләрен исәпкә алып эшләнде.

## 2. Сосновка авыл җирлегендә эшмәкәрлек һәм инвестицион климатка анализ

Сосновка авыл җирлеге территориясендә 2022 елның 1 гыйнварына 7 кече эшмәкәрлек субъекты теркәлгән. Уртача хезмәт хакы 9,8 мең сум тәшкил итә. Уртача

хезмәт хакы 2020 ел белән чагыштырганда 24% ка артты. Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының күбесе төзелеш, күпләп һәм ваклап сату өлкәсендә мәшгуль.

Үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан махсус инвестицион җәлеп итүчәнлеккә ия булган, үз мәйданнарына кече һәм урта бизнесның җитештерү объектларын кабул итәргә әзер булган җир кишәрлекләрен ачыклау һәм сайлап алу эше алып барыла.

Сосновка авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары
үсешенең төп индикаторлары

| Индикаторлар /еллар | 2020 | 2021 | 2022 |
|---|---|---|---|
| Барлыгы шәхси эшмәкәр теркәлгән, берәмлек | 9 | 9 | 10 |
| Кече предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача саны (тышкы ике урында эшләүчеләрдән тыш), кеше | 20 | 20 | 23 |
| Уртача айлык хезмәт хакы, сум | 7500 | 7900 | 9800 |

Сосновка авыл җирлеге эшмәкәрләре кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм программаларында катнашу мөмкинлегенә ия.

Тотрыклы үсеш һәм халыкның тормыш сыйфатын күтәрүнең мөһим факторы булып, Сосновка авыл җирлегенең инвестицион климаты һәм икътисадка инвестицияләр җәлеп итү тора.

«Россия терәге», «Эшлекле Россия» Стратегик инициативалар агентлыгы[1], шулай ук Татарстан Республикасының социаль - икътисадый мониторинг комитеты эшмәкәрлек берлеген анкеталау һәм сораштыру рәвешендә үткәрә торган тикшеренүләр нигезендә эшмәкәрлек һәм инвестицион климатны чагылдыручы төп проблемалар булып тора:

- салым салуның югары дәрәҗәсе;
- финанс чаралары җитмәү;
- дәүләт ягыннан ярдәм булмау;
- продукцияне сатуда кыенлыклар;
- аңлаешлы инфраструктура булмау;
- административ киртәләр

Сосновка авыл җирлеге территориясендә эшмәкәрлек һәм инвестицион климатны билгеләүче проблемалар үзара бәйләнешнең югары дәрәҗәсенә ия, шуңа күрә аларны хәл итү бюджет акчаларын максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган очракта, башкарма хакимият органнары сәясәтен эшмәкәрлек һәм инвестицион климатны үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерергә мөмкинлек бирүче программа-максатчан методтан файдалануны таләп итә.

## 3. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

3.1. Программаның төп максатлары:

– Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең социаль-икътисади мәсьәләләрен хәл итүдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм аларның ролен күтәрү өчен уңайлы шартлар тудыру;
– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының конкуренциягә сәләтлелеген тәэмин итү;

[1] Регионнарда инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы.

- кече һәм урта эшмәкәрлекнең гамәлдә булган субъектларын саклау һәм яңа субъектлар булдыру;
- җирле җитештерүчеләр товарлары һәм хезмәтләре белән базарның туендырылуы;
- Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына үзләре җитештерә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) алга этәрүдә булышлык күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек санының артуы;
- халыкны эш белән тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү;
- кече һәм урта эшмәкәрлеккә талантлы яшьләрне һәм потенциаль идарәчеләрне ачыклау һәм җәлеп итү;
- Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге предприятиеләре җитештергән тулаем продукция күләмендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештергән товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) өлешен арттыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларның салым керемнәрендә түләнгән салымнар өлешен арттыру.

3.2. Куелган максатларга ирешү өчен хәл ителергә тиешле бурычлар:

- Сосновка авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын үстерү;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең конкуренциягә сәләтлелеген һәм инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру;
- иҗтимагый һәм һөнәри оешмалар һәм эшмәкәрләр берләшмәләренең ролен көчәйтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм Сосновка авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация һәм оештыру ярдәме күрсәтү;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне төрле өлкәләрдә - торак-коммуналь, төзекләндерү, ремонт-төзелеш, җәмәгать туклануы өлкәләрендә муниципаль заказларны үтәүгә җәлеп итү;

Программаның бурычлары аның ахыргы максаты белән билгеләнә һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген активлаштыруга, яңа эш урыннары булдыруга һәм эшмәкәрлеккә җәлеп ителгән киң катлам халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә торган уңайлы мохит булдырудан гыйбарәт.

## 4. Программаның төп принциплары

Программаның төп принциплары:

- КУЭС ярдәм сорап мөрәҗәгать итүнең гариза бирү тәртибе;
- КУЭСка ярдәм инфраструктурасы;
- программада каралган критерийларга туры килгән КУЭСның тиешле программаларда катнашуга тигез керү мөмкинлеге;
- «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне үтәп ярдәм күрсәтү;
- ярдәм күрсәтү процедураларының ачыклыгы.

## 5. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа ысуллары белән чишү кирәклеген нигезләү

Кече һәм урта эшмәкәрлек Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең икътисадый һәм социаль бурычларын хәл итүдә мөһим роль уйный, чөнки ул яңа эш урыннары булдыруга, кулланучылар базарын товарлар һәм хезмәтләр белән баетуга, көндәшлекле мохит булдыруга ярдәм итә, халыкның икътисади мөстәкыйльлеген, салым керемнәренең тотрыклылыгын тәэмин итә. Эшмәкәрлекне үстерү Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешендә өстенлекле бурычларның берсе булып тора.

Сосновка авыл җирлеге территориясендә бүгенге көндә 7 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты эшли.

Сосновка авыл җирлегенең кече һәм урта предприятиеләре эшчәнлегенең төрләре буенча сәүдә, хезмәт күрсәтү, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өлкәләрен колачлый.

Кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенең уңай тенденцияләренә карамастан, бизнес үсешенә комачаулый торган проблемалар кала. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эре предприятиеләргә караганда азрак тотрыклылык һәм көндәшлеккә сәләтлелек белән характерлана, димәк, Сосновка авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан ярдәмгә мохтаҗ.

КУЭС үсешендәге комачаулык факторларын өч проблемага бүлеп була:

1. оештыру проблемалары (предприятиене юридик яктан рәсмиләштерүдә һәм теркәүдә кыенлыклар, үз эшеңне ачу һәм үстерү өчен кирәкле рөхсәт документларын алуда (лицензияләр һ. б.), банкта счет ачуда һ. б. проблемалар);

2. материаль-техник тәэмин итү (җитештерү һәм хезмәт урыннары, заманча җиһазлар җитмәү яки булмау, персоналның түбән квалификациясе, эшмәкәрлек эшчәнлегенең тиешенчә яклanmавы һ. б.);

3. матди-финанс проблемалары:

- предприятиене теркәү өчен капитал алуда кыенлыклар;
- әйләнештәге акчалар җитмәү;
- эшчәнлекне киңәйтү өчен үзеңнең һәм бурычка алынган финанс чаралары җитмәү.

КУЭСның күпчелеге финанс хәленең тотрыксыз булуы һәм акча җитмәү сәбәпле, үз үсешенә, яңа технологияләр кертүгә, продукциянең һәм хезмәтләрнең сыйфатын күтәрүгә, озак сроклы инвестицияләр кертүгә, яңа базарларны үзләштерүгә эчке стимуллардан мәхрүм.

Шулай ук эшмәкәрләргә идарә итү һәм коммерция карарлары кабул итү өчен бизнес алып баруның төрле аспектлары турында мәгълүмат кирәк. Кече һәм урта бизнесны мәгълүмати тәэмин итү проблемасы консультацияләү һәм мәгълүмати-аңлату чаралары үткәрү кебек традицион формаларны кулланып хәл ителергә мөмкин.

Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты кече һәм урта бизнесны социаль тотрыклылыкның ышанычлы гаранты итеп күрә һәм эшмәкәрлеккә сәләтле азкеремле һәм эшсез кешеләрне җәлеп итү бурычын хәл итә. Авыл җирлеге өчен кече һәм урта бизнес халыкны даими эш белән тәэмин итүнең ышанычлы чыганагы булып тора.

Авылның реаль икътисади потенциалы бетми, кече һәм урта бизнеста хәл ителергә тиешле проблемалар да аз түгел.

Программа кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү өчен норматив-хокукый база булдыру, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс, мәгълүмати, консультация һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү, шулай ук контроль процессын оештыру буенча комплекслы эш планы булып тора.

## 6. Программа чаралары системасы

Программа чараларын гамәлгә ашыру 2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы кысаларында җирле бюджет акчаларыннан, бюджеттан тыш фондлардан, эшмәкәрләрнең үз акчаларыннан, җәлеп ителгән инвестицияләрдән финанслау шартларында гамәлгә ашырыла.

Программа чаралары программа билгеләгән бурычлар нигезендә эшләнде.

2023-2027 елларга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы чаралары исемлеге

| № | Чара исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|
| 1. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартларны камиллəштерү | | | | |
| 1.1. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм аларга ярдәм итү мәсьәләләрен җайга сала торган муниципаль норматив - хокукый база булдыру | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |
| 1.2. | Кече эшмәкәрлек субъектларының муниципаль заказ урнаштыруда катнашуы мониторингы | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |
| 1.3. | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләре буенча аларның фикерләрен исәпкә алу максатында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен чагылдыручы коммерциячел булмаган оешмалар, эшмәкәрләрнең иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итү | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |
| 1.4. | Программа кысаларында ярдәм алучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары реестрын формалаштыру һәм алып бару | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |
| 1.5. | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар, крестьян фермер хуҗалыклары һәм башка авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре җитештерә торган хәзерләү продукциясе эшчәнлеген үстерү | Җирлек БК | 2023-2027 | җәлеп ителгән инвестицияләр булганда |
| 1.6. | Коррупциягә каршы рейтингларны формалаштыру механизмнарын эшләү һәм алга таба эшмәкәрләргә хәбәр итү юлы белән аны коррупциячеллеккә | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |

| № | Чара исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Финанслау чыганагы |
|---|---|---|---|---|
| | бәяләү | | | |
| 1.7. | Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары буенча эшлекле очрашулар, «түгәрәк өстәлләр» һәм семинарлар оештыруда һәм үткәрүдә катнашу | Җирлек БК, район башкарма комитеты (килештерү буенча) | 2023-2027 | Җирлек бюджеты |
| 1.8. | Татарстан Республикасы Икътисад һәм социаль үсеш министрлыгы һәм Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган федераль һәм региональ программаларда катнашу өчен эшмәкәрләргә конкурс документларын әзерләүдә булышлык итү | Җирлек БК, Түбән Кама муниципаль районы эшмәкәрләре Иҗтимагый советы | 2023-2027 | Татарстан Республикасы бюджеты[2] |
| 2. Түбән Кама муниципаль районының Сосновка авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасы эшчәнлеген тәэмин итү. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати, консультацион һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү | | | | |
| 2.1. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация ярдәмен гамәлгә ашыру һәм үстерү | Җирлек БК, Түбән Кама муниципаль районы эшмәкәрләре Иҗтимагый советы | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |
| 2.2. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |
| 3. Кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә социаль яклау һәм хезмәтне саклау механизмнарын эшләү һәм гамәлгә кертү | | | | |
| 3.1. | Хезмәтне саклау буенча эшләрне оештыру мәсьәләләрендә консультация-методик ярдәм | Җирлек БК | 2023-2027 | финанслау таләп ителми |

Кабул ителгән кыскартулар исемлеге
Җирлек БК - Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты
ЭИС –Түбән Кама муниципаль районы эшмәкәрләре Иҗтимагый советы

Программаның ресурс белән тәэмин ителеше бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акча тәшкил итә:

- федераль бюджет - федераль норматив хокукый актлар нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга Россия

[2] Бюджетара субсидияләр һәм субвенцияләр кысаларында

Федерациясе субъектларына конкурс нигезендә бүлеп бирелә торган акчалар (конкрет суммаларны күрсәтмичә мөмкин булган акча чыганагы буларак фаразлана);

- Татарстан Республикасы бюджеты - федераль норматив хокукый актлар нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләргә конкурс нигезендә бүлеп бирелә торган акчалар.
- Бюджеттан тыш чыганаклар.

Финанслау күләме ел саен үзгәртеп корылырга тиеш һәм бюджет акчаларын бүлүчеләрнең тиешле норматив-хокукый актлары белән раслана.

## 7. Программа белән идарә итүне оештыру (Программаны тормышка ашыру механизмы)

Программаны гамәлгә ашыру механизмы - ул билгеләнгән нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итә торган җаваплы башкаручыларга, сроклар буенча координацияләнгән программа чаралары системасы.

Программаның заказчысы булып Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты тора, аның бурычларына Программа чараларын үтәүне оештыру һәм башкаручыларның хезмәттәшлеген координацияләү керә.

Программа чараларын үтәү «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 8. Программаны тормышка ашыру барышын контрольдә тоту

Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты һәм Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге Советы программаның тормышка ашырылуын һәм бүлеп бирелә торган акчаларның үзләштерелүен контрольдә тота.

Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге башкарма комитеты ел саен Программаның үтәлеше турында Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге Советына хисап бирә.

## 9. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны гамәлгә ашыру тулаем авылдагы икътисади һәм социаль хәлгә уңай йогынты ясаячак, инвестицион климатны яхшыртуга, авыл инфраструктурасын үстерүгә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының конкуренциягә сәләтен арттыруга һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртуга ярдәм итәчәк.

Программаны гамәлгә ашыру кысаларында авылда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттырып, кече һәм урта эшмәкәрлек секторында халыкны тотрыклы эш белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру һәм Түбән Кама муниципаль районы Сосновка авыл җирлеге бюджетына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан салым һәм салым булмаган керемнәрне арттыру күздә тотыла.

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге Программа чараларын финанслау дәрәҗәсенә һәм аларның үтәлешенә бәйле.

2027 елга программа нәтиҗәләре түбәндәгеләр булырга тиеш:

– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;
– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача санын арттыру;
– кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салым керемнәрен арттыру;
– авыл инфраструктурасын үстерү һәм күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту;

- авылның кече эшмәкәрлекнең тармак структурасын авыл икътисадының өстенлекле тармакларында эшчәнлек алып баручы кече предприятиеләрнең өлешен арттыруга таба үзгәртү;
- кече бизнес оешмалары тарафыннан үзебездә җитештерелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм хезмәтләр күләмен арттыру.